РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**посёлка городского типа**
**КАМСКОЕ УСТЬЕ**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Советска, 11, пгт. Камское Устье, 422820
тел. (884377) 2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631, ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кама Тамагы**
**шәһәр тибындагы поселогы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 11,Кама Тамагы штп, 422820,
тел. (884377)2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631 ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 23 октябре** **№ 132**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга «Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы территориясендә төзекләндерү, энергетика нәтиҗәлелеген һәм юл куркынычсызлыгын арттыру» муниципаль программасын раслау турында»2015 елның 10 ноябрендәге № 115 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга «Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы

поселогы территориясендә төзекләндерү, энергетика нәтиҗәлелеген һәм юл куркынычсызлыгын арттыру» муниципаль программасын раслау турында»2015 елның 10 ноябрендәге № 115 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Программа атамасында «2016-2020» санын «2016-2024» санына алмаштырырга.

1.2. Программа паспортында:

а) «Программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру сроклары | 2016-2024 еллар» |

б) «Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлында:

беренче абзацта «48421,2» санын «92908,5» санына алмаштырырга;

алтынчы абзацта «2020 ел - 10340,0» санын «2020 ел - 11349,0» санына алмаштырырга;

җиденче – унынчы абзацлар белән тулыландырырга:

«2021 ел-11015,4 мең сум;

2022 ел -10720,0 мең сум;

2023 ел -10817,9 мең сум;

2024 ел -10925,0 мең сум»;

в) 2 пунктның егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2016-2024 еллар Программаны тормышка ашыру сроклары»;

г) 4 пунктның беренче абзацында икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2016-2024 елларда планлаштырылган чыгымнарның гомуми суммасы - 92908,5 мең сум».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Ф. Яруллин